**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ КОЛЧУРА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**КАРАРЫ**

2020 елның 27 августы                                        10№

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлеге Башкарма комитетының 2013 елның 8 октябрендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлеге территориясендә Җирләү урыннарын карап тоту кагыйдәләре турында"гы 37 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

1996 елның 12 гыйнварындагы «Җирләү һәм җирләү эше турында"гы 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлеге Башкарма комитетының 2013 елның 8 октябрендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлеге территориясендә Җирләү урыннарын карап тоту кагыйдәләре турында"гы 37 номерлы карарына (алга таба - Кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Кагыйдәләрнең 1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Җирләү урыннары булып этик, санитар һәм экологик таләпләр нигезендә бүлеп бирелгән, үлгән кешеләрнең җәсәдләрен (калдыкларын) күмү өчен аларда корылган зиратлар, җәсәдләр көле (үлгәннәрнең җәсәдләрен (калдыкларын) яндырганнан соң калган көл, алга таба – көл) салынган савытларны күмү өчен кайгы стеналары, мәрхүмнәрнең җәсәдләрен (калдыкларын) утка тапшыру өчен крематорийлар, шулай ук үлгән кешеләрне җирләү өчен билгеләнгән башка бина һәм корылмалары булган җир кишәрлекләре тора. Җирләү урыннары мәдәни-тарихи әһәмияткә ия булган объектларга карый ала.»

- Кагыйдәләрнең 2.7 пунктында «2.10 п.» сүзләрен «2.6 п.» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан(халыкка җиткерелгән) мизгелдән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Югары Колчура авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе:                    Е.В. Краснова